Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты
карары

25 февраль 2020 ел № 236

Территорияне ызанлау
проектын раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү һәм планировка структурасы элементларын бүлеп бирү максатларында, 2020 елның 13 февралендәге 1143и номерлы Әлмәт муниципаль районының Җирдән файдалану һәм авыл җирлекләрен төзү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча комиссия бәяләмәсе нигезендә,

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Зәйнуллина Мөслимә Әсгать кызына үз акчалары хисабына Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Колшәрип авыл җирлеге, Колшәрип авылы, Южная урамы, 10 з/у адресы буенча урнашкан 16:07:190001:770 кадастр номерлы җир кишәрлегенә карата кызыл сызыкларны үзгәртү өлешендә территорияне ызанлау проектын әзерләүгә керешергә тәкъдим итәргә.

2. Әлмәт муниципаль районының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесенә (Мордагулова Р.Р.) территорияне планлаштыру документларын әзерләү һәм карап тоту тәртибе, сроклары турында әлеге тәкъдимне кабул итүне һәм карауны тәэмин итәргә.

3. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары Д. В. Косаревка йөкләргә

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Н. Гирфанов